ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

# КАРАР

**«24» апрель 2023 ел.** **№11**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 08 сентябрендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 елгы 414-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексын, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге уставын гамәлгә ашыру, Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү өлкәсендә контрольне көчәйтү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 08 сентябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.7.1 пунктның 7 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы эшмәкәрләр хокукларын

яклау буенча вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов